ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 август 2015 ел № 4804

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге буенча торакның гомуми
мәйданының 1 квадрат метры өчен
бәя нормативы турында

Яр Чаллы шәһәре территориясендә «Россия гражданнарына – һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак» илкүләм проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 санлы карары белән расланган «2011-2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру уңаеннан, торак сатып алу (төзү) өчен яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү һәм алардан файдалану кагыйдәләренең 10 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 санлы карары белән расланган «2014-2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында, «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасына, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2015 елның икенче ярты еллыгына Россия Федерациясе буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы һәм 2015 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2015 елның 23 июнендәге 446/ПР санлы Боерыгына туры китереп,

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яшь гаиләләр өчен торак сатып алуга яки шәхси торак төзүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрына бәя нормативын 2015 елның өченче кварталына 32 983 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Д.В. Щербага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

Р.Ә. Абдуллин